СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №72 (7245) | 18 июнь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Эшнең кызу чагы

Ульянов исемендәге колхоз. Кырларда тракторлар шавы. Авыл халкы өчен эшнең кызу чагы җитте. Бу көннәрдә Т-70 тракторчылары Азат Әхмәтвәлиев, Рафик Шәрапов, Сәлим Әһлетдинов, Әсләм Галәветдиновларның да эшләре тыгыз. Алар чөгендернең рәт араларына икенче катка эшкәртү үткәрергә әзерләнәләр.

285 гектар мәйданны биләгән кырда чөгендерне сирәкләү эшләрендә мәктәп, китапханә, кибет, культура йорты, авыл Советы һәм колхоз бухгалтериясе аппараты эшчеләре дә булышалар.

## Нәтиҗәләре яхшы

Дуңгызлар симертү буенча хуҗалыкара берләшмә эшчәннәре агымдагы елны да яхшы күрсәткечләр белән башлап җибәрделәр. Линия операторлары Фәнил Хәбибуллович Хәмидуллин, Анатолий Александрович Захаров һәм эшчеләр Валентина Тимофеевна Маркова агымдагы елның 5 аенда үз карамакларындагы 100 килограммга кадәр симертелергә тиешле дуңгызлардан 472 шәр грамм уртача тәүлеклек үсеш алдылар.

Хуҗалык буенча исә уртача тәүлеклек артым 462 шәр грамм тәшкил итә.

**В. КУЗЬМИНА,**
баш бухгалтер.

## „Татарстан“ колхозыннан хәбәрләр

Фатыйма Шәяхмәтовадан: «Чөгендер игүдә ничәнче ел эшлисез?»—дип сорасаң: «Үземне белгәннән бирле», дияр. Бу чыннан да шулай. «Татарстан» колхозында татлы тамыр үстерүгә керешкән беренче елларны да хәтерлидер әле ул. Бу еллар уңышы сөендермәде. Туфрак банитеты ягыннан да мактанырлык түгел, тәҗрибә дә җитенкерәмәгәндер четрекле яңа культураны игүдә. Еллар узган саен шикәр чөгендере игү серләре ачыла барды, механизаторлар да, чөгендерче хатын-кызлар да зур тырышлык куйдылар, агротехникага да нык әһәмият бирелде. Ниһаять, бу культураны игүчеләр дә уңышка ирешә башладылар.

Чөгендерче Фатыйма Шәяхмәтова боларның барысын да үзе кичерде. Вакыт узган саен колхоз чөгендер мәйданын киңәйтә барды. Быел һәр чөгендерче хатын-кызга ул 5 әр гектарга якын беркетелгән. Рәт араларын беренче кат эшкәртү инде тәгәлләнгән. Татлы тамыр гөрләп үсә, уңышның мул буласына шик юк.

Чөгендер плантациясендә эш тәгәлләнгәч Ф. Шәяхмәтова икенче эшкә күчә.



Ул ел саен хуҗалыкның кирпеч заводында хезмәт итә, җәен кирпеч сугалар, кышын кирпечләрне яндыралар һәм елның-елында шулай. Хәер, алдынгы колхозчыга кышын-җәен хуҗалыкта эш бетми. Ул бер эштән дә баш тартмый, һәрчак алдынгылар сафында.

Рәсемдә: «Татарстан» колхозы чөгендер игүчесе Ф. Шәяхмәтова.

В. Никонорова фотосы.

## Яңа йортлар калка

«Татарстан» колхозы. Хуҗалыкта социаль-культура объектлары төзек, заманча—ул яктан кайгы юк. Хәзер биредә төп игътибар торак төзелешенә юнәлтелгән. Быел авылда 6 кеше индивидуаль төзелеш алып бара. Колхоз аларга һәрьяклап булышлык күрсәтә: 1 мең сум күләмендә ярдәм бирә, хуҗалыкта җитештерелгән кирпечнең 1 меңен 60 сум белән сата, транспорт, такта ярдыру хезмәтләрен бушлай күрсәтә. Болар һәммәсе төзелеш алып баручының чыгымнарын бермә-бер киметәләр.

Колхоз исә быел 30 башка исәпләнгән ана дуңгызлар абзары сала.

**Н. НАСЫЙБУЛЛИН,**
партоешма секретаре.

## Азык хәзерләнә

**Кузнецов исемендәге колхозда мул терлек азыгы әзерләү киң колач белән алып барыла. 36 гектар күпьеллык үлән мәйданыннан 20 тонна печән әзерләнде инде. Печән чабуда Петр Улопов аеруча тырышлык күрсәтә.**

**Шул ук вакытта хуҗалыкта яфрак азыгы әзерләү дә башланды.**

**А. ГАНИЕВ,**
баш бухгалтер.

## Уйланырга урын кала

Авыл халкының елына бер килә торган Сабантуй бәйрәмен авыл мулласы Гайнетдин бабай Үсманов фатихасы белән ачып җибәрделәр Колбай Морасада. Аннан колхоз рәисе Р. Р. Насыйбуллин авыл эшчәннәренең язгы басуда куйган тырыш хезмәтләрен билгеләп үтте, алдынгыларны игълан итте. Бригадалар арасында беренче урынны Н. Ибраһимов җитәкләгән 2 нче бригада алды, ә кыр батырлары арасында Ш. Миндубаев, М. Фәрдиев, Ә. Шәяхмәтов, И. Сучков кебек тәҗрибәле механизаторлар исеме аталды.

Ә аннан Сабантуй уеннары башланды. Мәйданга ярсу атлар килеп керде. Аларның иң җитезе итеп Ришат Гайнетдинов иярләгән ат табылды. Шуннан соң мәйданда чүлмәк вату, шома колгага менү, капчык киеп йөгерү, гер күтәрү, капчык сугышы—барысы да булды. Халыкның төп игътибарын, әлбәттә, татарча көрәш биләде. Ул быел да бик кызыклы барды. Сабантуйның быелгы төп батыры итеп электрик Илдар Йосыпов танылды, икенче урында Мөдәррис Хәйруллин, өченче урында Роберт Төхвәтуллин булдылар.

Сабантуй мәйданы бушап калды. Быел аннан таралучылар һәммәсе дә канәгать киттеләр димәс идек. Димәк, киләчәктә аны һәркем күңеленә хуш килерлек итеп оештыру турында уйланырга урын кала әле.

**Г. МУРЗИНА.**

## 1991 елның 12 июнендә Татарстан ССР Президентын сайлау буенча тавыш бирү ЙОМГАКЛАРЫ

33 нче номерлы Октябрь сайлау округы буенча округ сайлау комиссиясеннән алынган мәгълүматларга караганда сайлаулар барлык 55 сайлау участогында да үтте.

Татарстан ССР Президентын сайлаулар буенча тавыш бирү исемлегенә 38600 сайлаучы кертелгән иде. Тавыш бирүдә 30163 кеше катнашты. Татарстан ССР Президентлыгына кандидат М. Ш. Шәймиевны яклап 22379, ә каршы 7781 сайлаучы тавыш бирде.

РСФСР Президентын сайлау буенча исемлеккә 38201 сайлаучы кертелгән иде. Тавыш бирүдә 17507 кеше катнашты. В. В. Бакатинны яклап 608, ә каршы 16479; Б. Н. Ельцинны яклап 4826, каршы 12261; В. В. Жириновскийны яклап 1756, каршы 15331; А. М. Макашовны яклап 904, каршы 16183; Н. И. Рыжковны яклап 5520, каршы 11567; А. Г. Тулеевны яклап 2878, каршы 14209 кеше тавыш бирде.

## Депутат сайланды

1991 елның 12 июнендә 30 нчы номерлы Түбән Чаллы сайлау округы буенча киткән депутат урынына халык депутатларының район Советына депутат сайлау үткәрелде. Район Советы депутаты итеп 1952 елда туган район авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек идарәсе начальнигы Әнәс Нәбиуллович Рәхмәтуллин сайланды.

## Чөгендергә—удар хезмәт көне

XXI партсъезд исемендәге колхозның Т-70 тракторында өченче елын чөгендер игүче Рөстәм Сәмигуллович Хәйруллин үзен авыл өчен кирәкле кеше дип саный. Шуңа күрә дә армия сафларында хезмәт итеп кайткач та җиң сызганып эшкә керешә. Үзе чәчә, яфрак өсләрен ура, уңышны җыя. Кышын исә сарыклар карый.

Шундый уңган кеше барында, диләр чөгендер сирәкләүче апалар Мәдинә Минһаҗевна Касыймова, Фәния Хәмидулловна Рәхмәтуллиналар, эшләве дә рәхәт.

Чыннан да, Рөстәм Сәмигуллович рәт араларын эшкәртү технологиясен төгәл башкара, һәрнәрсәне үзе белеп эшли.

Мәдинә Минһаҗевна белән Фәния Хәмидулловна да эштә сынатмыйлар. Һәр елны чөгендер үстерәләр. Быел инде бу өлкәдә өч дистә елларын тутыралар.

Әнә шулай клхоз чөгендерчеләре беренче кат сирәкләү эшләрен тизрәк тәгәлләү өчен зур тырышлык куялар.

**Ш. ГАТИН.**

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ДӨНЬЯДА

**АКШ Президенты Дж. Буш СССР Президенты М. С. Горбачевка Кушма Штатларның Советлар Союзына Америкадан авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу өчен 1,5 миллиард доллар күләмендә кредит бирәчәген хәбәр итте. Американың рәсми вәкилләре әйтүенчә, бу кредит тугыз ай дәвамында өч этапта биреләчәк.**

x x x

**Австралия премьер-министры Роберт Хоук автомашинада хәвефсезлек каешын каптырмыйча гына барган өчен 80 доллар күләмендә штрафка тартылды. Премьер-министр кагыйдәне машинада барган килеш кенә телевидение өчен интервью биргәндә бозган. Брисбен шәһәре кешеләре телевизор экраннарында премьер-министрны хәвефсезлек каешыннан башка күрүгә, полициягә шалтыратырга тотыналар. Имеш, премьер-министр кагыйдәне боза, аңа тиз генә чара күрелсен.**

### ИЛДӘ

**Ташкенттагы имам Әл-Бохари исемендәге ислам институтында 70 хатын-кызга махсус курсларны тәмамлаулары турында таныклык бирелде. Берничә ай дәвамында кызлар балаларны шәригать кушканча тәрбияләргә өйрәнгәннәр. Ел ахырына кадәр әлеге курсларны 400 кеше тәмамлаячак. Ислам уку йортлары, ректор сүзләренә караганда, хәтта революциягә кадәр дә булмаган.**

x x x

**Таллинндагы хезмәт ресурслары биржасы эш урыннары бетерелү турында 612 хәбәр алды. 799 кеше эш сорап биржага мөрәҗәгать иткән.**

**Эшсез калган кешеләргә пособие күләме анда айга 108 сум тәшкил итә, шуңа естәп тагын 70 сум өстәмә пособие бирелә.**

**Район газетасына 60 яшь**

### Күп балалы аналарга пособие

1940 нчы елда район буенча 130 күп балалы аналар дәүләт пособиесе алдылар. Аларга бер ел эчендә барлыгы 290.000 сум акча бирелде.

«Приютовка» колхозы члены күп балалы Татьяна иптәш Прокопьева 18.000 сум, Чулпан авылыннан Мария иптәш Боброва 14.000 сум һәм Мария иптәш Груздева 12.000 сум пособие алдылар.

ЛЕВАГИН.
(«Октябрь колхозчысы»).
5 январь, 1941 ел.

### 5 ялгыз хуҗалык колхозга керде

Шушы елның 8 февралендә «Удар» колхозы членнарының гомуми җыелышы булып үтте.

Җыелышта авыл Советының 1941 нчы елгы бюджеты расланды һәм башкарма комитеты председателе иптәш Билаловның 1 нче квартал финанс планының үтәлеше турында кыскача информациясе тыңланды.

Аннан соң 5 аерым хуҗалыкның колхозга керү турында сорап язган гаризалары тикшерелде һәм бу хуҗалыкларны колхозга алу турында бертавыштан карар кабул ителде.

Колхоз председателе
Б. ГАЛИ.

### 15.130 сум отыш

Хезмәт ияләре үзләренең акчаларын заем тәртибендә дәүләткә биреп тору белән социалистик Ватаныбызга һәм үзләренә дә зур файда китерәләр.

Шушы елның январь аенда районыбызның хезмәт ияләре 224 облигациягә 15,130 сум отыш алдылар.

Ә. БАТЫРШИН,
саклык кассасы бүлеге мөдире.
(«Октябрь колхозчысы»).
14 февраль, 1941 ел. №6.

### Татар телен өйрәнү түгәрәге

Район үзәге партия активлары өчен ВКП(б) райкомы каршында татар теле өйрәнү түгәрәге оештырылып, а н д а план буенча барлыгы 8 тапкыр занятие үткәрелде.

Занятиеләргә Медянцев, Трифонов, Самсонов һәм башка иптәшләр аеруча зур активлык белән катнашалар. Алар татар телен системалы рәвештә өйрәнәләр.

М. ГАЛЛЯМОВА.
(«Октябрь колхозчысы»).
11 май, 1941 ел. №24.

# Мөстәкыйльлек гамәлгә ашсын

Бүгенге көндә СССРда 7 миллионга якын татар яши. Идел буенда, Уралда, Себердә, Үзәк Европада, гомумән, Литвадан алып Тын океанга кадәр сибелгән.

Иң күп халыклы милләтләрнең берсе булса да, югалуга йөз тоткан иде инде ул. Миллион ярымга якын татарның туган телендә сөйләшә белмәве, телен саклаганнарның күбесенең дә русча фикерләве берәү өчен дә сер түгел хәзер. Дистәләрчә еллар буена «милләтләрнең чәчәк атуы һәм үзара якыная баруы» сәясәте нәтиҗәсендә илебездәге күпме халык үзенең телен, мәдәниятын югалтты. Ассимиляция татар халкы йотылу процессын да тизләтте. 60 еллардан башлап сәясәт мәдәни, рухи гына түгел, аның нигезен тәшкил иткән телен бетерүгә юнәлдерелгән иде. Татар телендә укыту гадәттән тыш кысылды. Эш кәгазьләре, вузларда укыту рус телендә генә калды. Шуңа барып җитте ки, үз милләтләрен яшерү, аннан куркучылар да булды. Бәхеткә каршы, яшисебез бар икән әле, үзгәртеп корулар башланды.

Милләтне үстерү өчен хәзер мөмкинлекләребез киңәйде. Үткән ел 30 августта ТССР Югары Советы дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте. Бу документта җөмһүриятебез мөстәкыйль дәүләт, татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип игълан ителде.

Бу хакта күп сөйләнә һәм языла, әмма аңа кабат әйләнеп кайтуны урынлы саныйм. Декларация ТССРның барлык төр табигый байлыкларына, җир һәм урманнарына халкыбыз үзе хуҗа дип игълан итә. Моны мин иң зур казаныш саныйм. Югыйсә, 2,5 млрд.тонна нефтебезне «Дуслык» үткәргече буенча Көнбатыш Европага агызып үзебезгә ни алдык? Ил казнасына агылган йөз миллиардларча долларның күпмесе безгә эләкте? Тамчылары бер дә таммагандыр дип әйтмим, әмма алар табигатькә китергән зыянны да капламаганын әйтә алам. Җирсуга, үзебез җитештергән продукциягә хуҗа булсак, мондый хәлгә калмас идек, билгеле.

Мөстәкыйльлек әнә шулай үз байлыгыбызга хуҗа булу өчен кирәк. Шулай була икән, җөмһүриятебез нык үсәчәк. Моның өчен материаль, ягъни акча средстволары булачак.

Союздаш республика хокукына ия булу иҗтимагый һәм мәдәни үсеш өчен дә бик кирәк. Союздаш республикаларның һәркайсының Фәннәр Академиясе, киностудиясе бар. Халык санына уртача профессиональ театрлары әллә ничә тапкыр артты. Милли газета-журналлары, әдәби китаплар чыгару мөмкинлекләре дә бездәгедән күпкә иркен. Суверенлык өчен без шуңа күрә дә көрәшәбез.

Татарстан җирендә гасырлар буена татарлар, руслар, чувашлар һәм башка милләт вәкилләре бердәм һәм тату булып яшәде. Төрле милләттән булган авыллар халкы бер-берсенә кунакка йөрешә. Татар белән чуваш (Салдакай авылы), рус, татар (Чулпан, Савин), татар, рус һәм чуваш (Төрнәс, Мамык. Андреевка) авылларында интернациональ гаиләләр бик күп. Әмма җөмһүриятебез мөстәкыйльлек яулагач, элекке дус-ишләребез арасында татарларга шикләнеп караучылар аз түгел. Бу нилектән килеп чыга? Татарлар тулы ирек алса, башка милләтләрне кысу, кыерсыту башланмасмы, янәсе. Тагын бер сәбәп: үз милләтләрен, мәдәниятларын үстерүгә генә игътибар бирмәсләрме? Бу уңайдан шуны әйтәсем килә: суверенлык безгә, беренче чиратта, үз байлыкларыбызга хуҗа булу өчен, кирәк. Җөмһүриятебез бай булса, анда яшәүчеләрнең материаль, социаль хәле дә яхшырыр. Ә үзара мөнәсәбәтләргә килгәндә, милләтенә карамастан бер-береңне ихтирам итеп яшәү кирәк—безнең максат бары шул. Декларациядә шулар бәян ителә дә.

Милли үсеш мәсьәләсенә килгәндә һәр халык аның турында кайгыртырга бурычлы. Әйтик, милли гадәт, йолаларны торгызу, традицияләрне яңарту турында сүз алып барабыз икән, аны татарга, чувашка да әзерләп китереп бирмәсләр, үзебезгә тырышырга, инициатива күрсәтергә һәм шул юнәлештә өзлекле эш алып барырга кирәк.

Сүз уңаеннан бу юнәлештә иң беренче булып милли телләрне, мәдәниятны үстерү юнәлешендә эш алып бару кирәк. Шәһәрдә балалар бакчаларында милли группалар оештыру, класслар ачудан башлау кирәк. Элек Норлатта мәктәпләрдә параллель татар класслары бар, балалар туган телләрендә белем алалар иде. Аларны кабат ачу милли хәзерлекле кадрлар булдыру, фән, әдәбият һәм мәдәниятыбызне үстерү өлкәсендә алга таба беренче адым булыр иде. Казанда милли гиманазияләр ачу юнәлешендә шактый эш башкарылды. Ул агымдагы елда да дәвам иттерелә. Безнең район халык мәгарифе бүлегенең дә шәһәрдә татар телен укыту мәсьәләсендә планнарын беләсе иде. Бүген бу хакта уйланырга вакыт, минемчә. Суверенлык, кәгазьдә генә калмасын, халкыбызның рухи һәм һәрьяклы үсеше юлына басу өчен иң беренче адым шуннан башлана, югыйсә.

М. ГЫЙМРАНОВ.
Норлат шәһәре.

● „Патриот“

## Матрос батырлыгы

Кайтырына өч ай калган иде...
Эх-х бу язмыш, адәм баласын,
Нигә шулай алып китте икән
Ата-ананың йөрәк парәсен.

Бу юлларны редакциягә Колбай Мораса авылыннан Шакирҗан Шәйхиев язып җибәргән шигырьдән алдык. Шигырь флотта хезмәт срогын узучы, хәрби заданиене үтәгәндә һәлак булган якташыбыз Хәбир Дәүләтшинга багышлап язылган Анда ул Хәбирнең әти-әнисенең зур югалтуны авыр кичерүләре турында тирән борчылу, ачыну хисе саклаган хәлдә яза.

...Хәбирне авылдашлары бары җылы фикер белән генә телгә алалар. Иптәшләреннән бер ягы белән дә аерылып тормый торган малай булып үсә ул. Сабыр табигатьле, тыйнак һәм тыңлаучан, кешегә ярдәм итәргә һәрчак әзер булып үсә.

—Ул спортны бик ярата иде,—ди мәрхүмнең элекке класс җитәкчесе Рамил Сафин. —Чаңгыда оста шуа, гер күтәрү белән мавыга һәм, яшьтәшләре шикелле үк, техника белән ныклап кызыксына иде.

Ә эшкә дисәң бер төреннән дә тартынып тормый. Мәктәптә укыган елларында ук, җәйге каникулга чыгуга, әтисе белән маллар көтәргә басуга чыгып китә. Эсседә дә, салкынында, кояшында һәм яңгырында да туган як басуларында була. Күзен мәктәпкә кояшта каралып, чыныгып килә.

Туган ягын бик тә ярата Хәбир. Мәктәпне тәмамлагач та, һич уйланып тормыча колхозда эшкә кала. Хәрби хезмәткә чакыру кәгазе килгәч тә, нибары берничә көн генә ял итеп кала.

Туган якның шифалы кочагында чыныгып үскән, иркен сулышлы, киң күкрәкле яшь егетне флотка хезмәткә чакыралар. Матрос хезмәтенең бар нечкәлекләрен башыннан кичерә, диңгез суының тозлы тәмен татый. Гади матростан 2 статья старшинага кадәр үскәнче хезмәт иткән корабле палубасына үзенең дә тозлы тире аз таммый. Приморье краеның кырыс табигатенә, иксез-чиксез океан чайкавына да күнегә.

Әти-әнисен, туган ягын сагынып еш хатлары килә Хәбирнең. Хәрби хезмәт срогын тутыргач, кабат шунда әйләнеп кайтырга, колхозда эшләргә исәп тотуы турында яза. Хезмәт срогының ике ел ярымы үтеп өлгергән, хәрби тормышка тулысынча күнеккән инде.

Шуңа хезмәте дә, кем әйтмешли, җырлап бара. Командирларының боерыгын төгәл үти, җитезлек һәм тапкырлык күрсәтә. Шуның өчен аңа ялга кайтып килергә рөхсәт ителә. Атна-ун көннән юлга чыгарга тиеш була. Ләкин шулай килеп чыга ки, әти-әнисе, туганнары аны цинк гробта гына күрәләр.

...1991 елның 18 мартында, комсомолец Дәүләтшин хезмәт иткән корабль базада торганда, экипаж гомеренә куркыныч янаучы ситуация килеп туа. Беренчеләрдән булып, куркыныч турында уйлап тормастан, иптәшләрен коткарырга Хәбир Дәүләтшин ташлана. Ул сугышчан бурычын азагынача үти, үзе үлә, әмма хезмәттәшләренең тормышын саклап кала. Иптәшләрен коткарганда кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен Дәүләтшин хөкүмәт бүләгенә тәкъдим ителә.

Хәбирне бөтен авыл катнашында олылап җирләделәр. Ә курку белмәс матросның батырлыгы якташлары күңелендә саклана һәм сакланыр.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.



## Алдынгыларның берсе

«Рассвет» совхозының икенче товарлыклы-сөтчелек фермасы сыер савучысы Рәшидә Минвафовна Шәрипова үз эшенең чын остасы. Малкайлардан сыйфатлы продукт алу өчен ул вакытын да, көчен дә кызганмый.

Баштагы елларны чөгендерче булып эшләгән бу савымчының фермада инде 20 еллык эш стажы бар. Тырышлыгы, булганлыгы аркасында ул быел да яхшы нәтиҗәләргә ирешә. 1 июньгә үз карамагындагы сыерлардан 1502 килограмм сөт сауды. Хуҗалык буенча исә ул 1482 килограмм.

Шунысын да әйтергә кирәк, Рәшидә Минвафовнаның ире Хәниф, улы Әхмәт тә терлекчеләр.

Рәсемдә сыер савучы Р. М. Шәрипова.

## Чемоданнары әзер

**СССРдан китү һәм килү турында закон кабул ителүгә бәйле рәвештә илдән китүчеләрнең ихтимал саны да атала. Бу сан 500 меңнән алып 20 миллионга кадәр булыр дип көтелә.**

Ачыкланганча, Мәскәү кешеләренең 10 проценты якындагы өч елда берничә елга илдән китеп торырга ниятли. Һәм аларның һәркайсы үзе белән гаиләсен, дусларын алырга тели.

Университет белемле кешеләр арасында китәргә теләүчеләр урта махсус белемле кешеләр белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк. Әгәр эшчеләрнең 7 проценты гына чит илләрдә бәхет эзләргә теләк белдерсә, югары урыннар биләүчеләр арасында аларның саны 25 процент.

Алар яшәү өчен сайлаган илләр арасында АКШ беренче урында тора, аннары Европа илләре. Израильгә совет гражданнарының 3 проценты гына җыена.

### «АГРОПРИБОР» ФӘННИ-ПРОИЗВОДСТВО БЕРЛӘШМӘСЕ



**Фәнни-техник тикшерүләрнең, производствоның нәтиҗәлелеген күтәрү, авыл хуҗалыгына агрохимик хезмәт күрсәтү өлкәсендә приборлар, техник средстволар, системалар һәм технологияләр кертү һәм аларга хезмәт күрсәтү максатларында 1979 елда «Агроприбор» фәнни-производство берләшмәсе оештырылган иде.**

**«Агроприбор» фәнни-производство берләшмәсе хәл итә торган мәсьәләләр арасында авыл хуҗалыгы продукциясе сыйфатына контроль оештыру өчен үлчәү приборлары һәм автоматлаштырылган системалар, технологик тәэмин итү, үсемлекләрне һәм тирә-юнь мохитны саклау средстволары эшләү, агрохимик хезмәт күрсәтүне метрологик тәэмин итү һәм башкалар.**

**Рәсемдә: өлкән фәнни хезмәткәр, биология фәннәре кандидаты Н. М. Расницына колорада коңгызын, Америка ак күбәләген һәм башка корткычларны юк итү өчен массовый төстә кандала үрчетү җайланмасын сыный. Шунысы игътибарга лаек, корткычлар юк ителгәч, бөҗәкләр дә һәлак була.**

◆ **Хатын-кыз һәм производство**

# Матур киендерәләр

Соңгы вакытларда яшьләр һәм урта яшьләрдәгеләр арасында бәйләгән кофталар аеруча популярлык казанды.

Норлаттагы трикотаж әйберләре бәйләү һәм ремонтлау ательесында нәкъ менә шундый заказлар кабул ителә дә. Тик, соңгы вакытларда ихтыяҗның аеруча артуы сәбәпле, көнгә җитмешәр заказ кабул итәргә туры килде һәм хәзергә шуның өчен аны туктатып торырга булдык.

Ательеда нинди төр трикотаж әйберләре җитештерелгәнен күпләр белмиләр дә әле. Таныш булыгыз: ярымйоннан һәм синтетикадан спорт чалбарлары, җәйге ир-ат, хатын-кыз джемперлары, итәкләр, яшьләр өчен чигүле күлмәкләр, гольфилар, бизәкләп эшләнгән колготкилар, балалар башлыклары, жакетлар, чиста йоннан кофталар.

Хезмәт коллективында элекке елларны айлык план 20—25 мең сумга үтәлсә, хәзер ул 40—47 мең сумга җитте. Моңа ничек ирештек? Җавап кыска: машиналарның тоткарлыксыз, төгәл эшләве, эшчеләрнең намус белән, зур тырышлык куеп хезмәт куюлары аркасында. Бездә дә ялкаулар, вакыт узсынга йөрүчеләр байтак иде. Андыйлардан әкренләп арындык. Шундый карашлы эшчеләрне берәү дә хөрмәт итми.

Коллектив тулысынча яшьләрдән тора. Шунлыктан авырлыклар җитәрлек. 117 эшченең бүгенгесе көндә 42 се декрет ялында, больничный лист алучыларның саны да аз түгел. Бик тә кыен очракларда ялдагы эшчеләрне чакырабыз. Җиденче елын тегүче-моторист булып эшләүче Рәхилә Вәгыйзовна Хәбибуллинаны декрет ялыннан чакырып китердек. Үзенең эше муеннан, мал-туарын, балаларын да карыйсы бар, җитмәсә йорт салалар. Шулай да ризалашты ул. Планнарны Рәхилә Вәгыйзовна 180—200 процентка үти.

Эшчеләребез хезмәтенә карап акчасын алалар. Тегүче-моторист Зинаида Алексеевна Сидорова узган айда 1700, Вера Ивановна Зюзляева 740, тагын берничә эшче шул күләмдә хезмәт хакы алдылар. Дөрес, алар эшкә иртәнге сәгать сигездә түгел, инде җидедә киләләр.

Безнең эштә барысы да үзенчә бәйле. Пресслап торучы Татьяна Викторовна Орешинага бу төшенчә яхшы таныш, шуңа да өлгер ул. Берүк вакытта Татьяна кофталарны пресслый, җепне машинага чорный, лампас тасмалары әзерли. Ә кисүче Елена Константиновна Михеевага килсәк, ул бирегә оешма ачылган көннән бирле эшли һәм аңардан әле беравнең дә канәгатьсезлек күрсәткәне юк. Тегүче-моторист Нина Николаевна Петрова да үз эшен һәрчак сыйфатлы итеп башкара. Миннән еш кына: «Сез планнарны икеләтә арттырып үтисез, ә кайда соң товарларыгыз?» дип сорыйлар. Дөрестән дә, һәр эшнең үз хикмәте бар дигән шикелле, без трикотаж әйберләрен башлыча авыл җирләрендә яшәүче халык өчен җитештерәбез һәм товарларны шул рәвешчә реализацияләбез дә. Аннары Чирмешән районына да элекке еллардагы шикелле 8 мең сумлык хезмәт күрсәттек. Дөрес, бу мәсьәлә хәзер көн кадагында тора. Ул уңай хәл ителсә, бәлкем товарларны чит-ят районнарга озатуны туктатырбыз. (Үзебезгә җитешмәгәндә дию ем). Эшләргә мөмкинлекләр бар. Ә менә чимал табу авыр проблемаларның берсенә әйләнде. Аны эзләп Ульяновск, Димитровград шәһәрләренә барабыз. Республикабызда инде чимал җитешмәү сәбәпле күп кенә предприятиеләр ябылды яисә ябылу алдында тора. Бу курыныч безне читләтеп үтәрме? Җавап бирүе кыен.

**Л. КАБАНОВА,**
трикотаж әйберләре җитештерү һәм ремонтлау ательесы мөдире.



**УКРАИНА ССР. Волыньдагы Маневический май заводы катгый радиация контроле зонасында эшли. Чернобыль фаҗигасе бирегә дә үз эзен калдырган. Хәер, Ровен АЭСы да моннан 20 километрда гына. Заводта Маневический һәм Киверцов районнары хуҗалыкларыннан килгән чималга радиологик контрольлек итүче махсус служба эшли. Завод территориясенең һәм сөт китерүче техниканың радиацион чисталыгын тикшерү мәҗбүри. Махсус стендлардагы материалларда радиацион хәлнең торышы турында даими хәбәр ителә.**

**Предприятие радиологлары үткәргән тикшеренүләр соңгы елларда чималның «пычрануы» сөт промышленностенда кабул ителгән вакытлыча нормалардан артмавын күрсәтә.**

**Рәсемдә: предприятиенең производство начальнигы В. В. Булик һәм җайланмаларны көйләү буенча белгеч В. П. Устимов (икенче планда) транспорт средстволарының чисталыгына радиологик контроль үткәрә.**

**(УКРинформ—ТАСС).**

**«Россия» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында эштә уңган һәм булган бозау караучылар байтак. Шундыйлардан Нина Владимировна Осипова һәм Мария Григорьевна Павлованың исем-фамилияләрен атарга була.**

**Нина Владимировна профилакторий группасындагы бозаулардан 847, ә Мария Григорьевна дүрт айга кадәр булган бозаулардан 539 грамм уртача тәүлеклек артым алуга ирештеләр.**

**Рәсемдә: бозау караучылар Н. В. Осипова, ферма мөдире И. И. Яллин һәм М. Г. Павлова.**



# Рәхмәтемнең олысы сиңа, укытучы

Аллы-гөлле чәчәкләрне хәтерләткән шат һәм көләч йөзле балаларның җәйге каникулга чыгып шатлана-шатлана мәктәптән кайтуларын күзәтәм.

Соңгы кыңгырау чыңы күңелнең әллә нинди нечкә кылларына кагыла, хәтердә кадерле хатирәләрне уята. Мәктәп бусагасын атлап кергән көннән бирле күпме еллар үткән, күпме сулар аккан, шулай да олы җанлы, ягымлы йөзле укытучыларым бүген дә күз алдымда. Без аларның образын гомер буе йөрәк түребездә йөртәбез, тормышта аларга охшарга тырышабыз. Байлык һәм гүзәллек чыганагы—җиранабызга көчле мәхәббәт, кешене бизи торган күркәм сыйфатлар—гадилек, тугърылык, әдәп, намус, шәфкать, вөҗдан сафлыгы тәрбияләүче укытучыларымның барысына да—беренче хәреф танытучым Шәмсегаян апа Әюпова, биология укытучысы Нурҗиһан апа Хәбибуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Диләфкәр апа Сатдаровага гомерем буена рәхмәт укыйм, гомер буе аларны сагынып яшим.

Авылым мәктәбе! Синең яныңнан үткәндә, һәрвакыт дулкынланып узам. Дүрт балам синдә укып тормыш юлына киттеләр. Туган нигезгә җыелган чакларында һәркайсы үз укытучыларын сагынып сөйләшеп утыралар.

Кече улым Исхакның беренче укытучысы Мария Ивановна Щербакова лаеклы ялда. 30 елдан артык балаларга төпле белем биргән ягымлы, мөлаем йөзле укытучы Заречный поселогында яши. Исхак улымның армия хезмәтеннән кайтуына 4 ел вакыт үтеп китте. Гаиләсе, 2 баласы бар. Ә үзе Мария Ивановнаның кечкенә генә рәсемен 4 класстан бирле күкрәк кесәсендә йөртә.

«Бервакыт хезмәт иткәндә,—дип искә ала ул,—6—7 километр ераклыктагы пунктка илтү өчен ашыгыч хәрби задание бирделәр. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төндә тайга сукмагы буйлап барам: шомлы, куркыныч. Шулвакыт Мария Ивановнаның «Авырлыклардан курыкмагыз, һәрвакыт батыр һәм кыю булыгыз, түзем булыгыз», дигән сүзләре күңелемә килде. Гүя ул янымда минем белән янәшә бара, шик-шөбһәләрем юкка чыкты, күкрәк кесәмдәге рәсемен капшап карыйм. Кечкенә генә рәсем. Укытучымның якты образы барыр юлымны яктырткандай булды, һәрвакыт авырлыкларны җиңәргә көч бирде»,— дип ихластан дулкынланып искә ала үз укытучысын.

Гомер агымсулар кебек үтә. 6 яшьтән укырга кергән оныгым Кадрия дә 4 класс тәмамлады. Тирән кичерешләр белән аны каршылыйм, ләкин ул мәктәптән бик күңелсезләнеп кайтты. «Кызым, нигә кәефең юк, әллә берәр фәннән 3 ле чыктымы?»—дип сорыйм, ашыгып көндәлеген карыйм. Өчлесе юк, 4—5 билгеләре. Ә ул күңелсез генә: «Разия Гәрәевна безне беркайчан укытмаячак, алар семьялары белән башка җиргә китәләр. 5 нче класста безне төрле укытучы укытачак,—дип тирән көрсенде. Мин аны беркайчан да оныта алмам инде»—дип итәгемә башын куеп елый башлады.

10 яше дә тулмаган баланың күңелендә укытучысына булган олы ихтирам хисе саф яшьләр булып итәгемә тама.

Үз укытучыларымнан елый-елый аерылган балачагым искә төште...

Авыр сугыш еллары. Китап-дәфтәрләр юк. Класслар салкын. Өс-баш сәләмә, балалар суыктан күшегеп бөрешкәннәр. Һәрвакыт ашыйсы килә, туйганчы ашарлык ризык юк. Шуның өстенә әле бер баланың, әле икенчесенең әтиләре сугыш кырында үлеп калу турында да хәбәр килә.

Әтисен мәңгегә югалткан классташымның ачыргаланып: «Әтисез ничек яшәрбез?»—дип елавына барыбыз да парта өстенә капланып үксибез. Укытучы күз яшьләрен безгә күрсәтмәс өчен тәрәзәдән урамга карый, яңак сөякләре кысылып-кысылып ала. Явыз дошманга карата булган нәфрәттән тешләрен кыса. Өстендәге пальтосын салып салкыннан һәм кайгыдан калтыранган баланы төрә. Ә без бәрәңге җаймәләребезне классташыбызның алдына этәбез. Ашыйсы бик килсә дә ул ашый алмый, тамагыннан төшми.

Авыр уйлардан аерылып, яңа форма күлмәк, ак альяпкыч кигән, кызыл галстук таккан оныгыма сокланып карыйм.

Икенче класска кадәр тартып-сузып 3 легә укучы оныгым Разия Гәрәевна укыта башлагач көннән-көн яхшы билгеләре ала башлады. 20 еллык эш тәҗрибәсе булган педагог балалар күңеленә ачкыч тапты, бөтен көчен, белемен биреп, белем чишмәсенең юлларын ачты, аларның мәхәббәтен яулады. 4 нче класс укучылары тулы өлгереш белән 5 нче класска күчте, ата-аналарның башлангыч классларны олы, тәҗрибәле укытучыларга тапшырырга дигән тәкъдиме бик урынлы. Ә андыйлар бездә аз түгел. Чулпан урта мәктәбе коллективы һәм ата-аналары Разия Гәрәевна Хәсәнова, Лидия Ивановна Егорова, Исхак Минхәерович Мингалимов, Минәсма Билаловна Сафиуллина, Татарстанның атказанган укытучысы Татьяна Геннадьевна Прокопьева кебек тынгысыз, таләпчән тәрбияче, ягымлы, олы җанлы педагогларны белән хаклы рәвештә горурлана.

...Җәйге каникулга таралышкан балалар төркеме шундый татлы да, ачы да хатирәләр уятты.

**М. УСМАНОВА.**

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**СИШӘМБЕ**
**18 ИЮНЬ**
**ҚАЗАН ҚҮРСӘТӘ**

17.05 Мультфильм.
17.15 Шигърият. Л. Лерон.
17.25 Нәфис фильм: «Бакчачы».
19.00 Татарстан.
19.30 Актуаль әңгәмә. Гимназиядән—лицейга. Ике уку йортының иҗади хезмәттәшлеге турында репортаж.
19.40 Яшьләр иҗаты. Шагыйрә И. Ихсанова, җырчылар З. Фәрхетдинова, З. Билалов.
20.15 Тыныч йокы, нәниләр.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.40 Чаллы шәһәрендә сәламәтлек һәм матурлык бәйрәме.
21.10 «НЛО—мистикамы, әллә чынбарлыкмы?» Аномаль зонага экспедициягә барган К. Шакиров белән әңгәмә.
21.25 Игъланнар.
21.35 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Иртә.
9.05 «Бытбылдык елавы». 7 нче серия.
10.15 Балалар сәгате.
11.15 Мультфильм.
11.35 Совет җырлары концерты.
12.00 ТЯХ.
12.15 Актуаль репортаж.
12.30 Фильм-спектакль: «Рудольфо». Авторы—В. Распутин.
13.45 Док. фильм:«Күпер».
14.35 Яраткан вальслар. Концерт.
15.00 ТЯХ.
15.15 Нәфис фильм: «Ургылып аккан суның чоңгылында». 2 серия.
16.30 Һәвәсләр дөньясы.
16.45 Мультфильм.
16.55 Балалар өчен фильм: «Күңелле өч смена». 2 серия.
18.00 Безнең бакча.
18.30 ТЯХ.
18.45 Мультфильм.
19.00 «Сугышны каһәр суксын». 2 нче фильм.
19.35 Й. Гайдн. Труба белән оркестр өчен ми-бемоль мажор концерты.
19.50 «Бытбылдык елавы». 7 серия.
21.00 Вакыт.
21.40 «Озаттылар мине сугышка». Язучылар сугыш турында.
22.40 Актуаль интервью.
22.50 Нәфис фильм: «Зеро шәһәре».
00.30 ТЯХ.
00.50 В. Писарев бии.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильмнар.
8.50 Адам Смит акчалары
9.25 Мизгел, туктап кал.
9.55 Ритмлы гимнастика.
10.25 Нәфис фильм: «Берьюлы уйнау сеансы».
11.30 Док. фильм: «Жданов—Сталин яклаган кеше».
12.15 Башка сәнгать. 2 нче тапшыру.
12.45 Кристиана Лакруаның сихри модасы.
13.30 Балалар өчен фильм: «Ә шарчык һаман оча».
14.05 Солдат мемуарлары. 6 нчы фильм.
21.40 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.25 Док. фильм премьерасы: «Фасад артында».
22.50 Зурлар өчен мультфильмнар.
23.00 Хәбәрләр.
23.15 Бишенче тәгәрмәч.

**ЧӘРШӘМБЕ**
**19 ИЮНЬ**
**ҚАЗАН ҚҮРСӘТӘ**

17.05 ГО турында халыкка киноплакат.
17.25 Игъланнар.
17.30 Нәфис фильм: «Көчле рухлылар». 1 серия.
19.00 Татарстан.
19.30 Актуаль әңгәмә. Мәктәп һәм милләтнең киләчәге. Тапшыруда ТССР халык мәгарифе министры В. Гайфуллин катнаша.
19.45 Батырлар һәм көчлеләр спорты. Казанда ачылган каратэ беренчелегеннән репортаж.
20.25 Әлли-бәлли-бәү.
20.35 Телесеанс. Авыл яшьләре өчен тапшыру.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Иртә.
9.05 «Бытбылдык елавы». 8 серия.
10.15 Балаларның музыка клубы.
11.00 «Озаттылар мине сугышка». Язучылар сугыш турында.
12.00 ТЯХ.
12.15 Эшлекле курьер.
12.30 Нәфис фильм: «Зеро шәһәре».
14.10 Док. фильм: «Аерым географик нокта».
14.30 Мультфильмнар.
15.00 ТЯХ.
15.15 Нәфис телефильм: «Ике тавыш өчен көй». 1 серия.
16.25 Һәвәсләр дөньясы.
16.40 Балалар өчен фильм: «Күңелле өч смена». 3 серия.
17.45 С. Танеев. «Симфония №4. До минор. 12 нче әсәр.
18.30 ТЯХ.
18.45 Эшлекле курьер.
19.00 «Сугышны каһәр суксын». 3 нче фильм.
19.30 «Россия, исеңә төшер әле...» СССРның халык артисткасы Н. Сазонова хатирәләре.
19.55 «Бытбылдык елавы». 8 серия.
21.00 Вакыт.
21.40 Кеше һәм закон.
22.55 «Җыр-91».
23.50 ТЯХ.
00.10 Күптән узган еллар аһәңе». Киноконцерт.
01.00 Док. фильм: «Аны җир шарына күмеп куйдылар».
01.45 Н. Мясковский.«Аластор» симфоник поэмасы.
02.55 «Бытбылдык елавы». 8 серия.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Т. Николаева уйный (фортепьяно).
9.00 Россия, әйләнеп кара.
10.00 Мультфильм.
10.10 О. Иоселиани. «Йолдыз яву». Фильм-спектакль.
11.30 Док. фильм: «Беловодьсны эзләүчеләр».
12.20 Мстислав Ростропович. Рококо стилендә фантазия.
12.40 Док. фильм.
13.30 Фильм-спектакль: «Безнең Чукоккала».
14.25 Док. фильм: «Кем сулдан атлый?»
21.45 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
22.30 П. И. Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл» балетыннан концерт сюиталары.
23.00 Хәбәрләр.
23.15 Нәфис фильм: «Әтисе, әнисе һәм балалары».

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**
**20 ИЮНЬ**
**ҚАЗАН ҚҮРСӘТӘ**

17.00 Иң матур җыр. «Мәгариф» журналы үткәргән балалар җыры конкурсы.
17.20 Нәфис фильм: «Көчле рухлылар». 2 серия.
19.00 Татарстан.
19.30 Депутат каналы. Шәфкатьлелек мәсьәләләре турында.
20.15 Тыныч йокы, нәниләр.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.45 Фильм-концерт: «Июньдә ярты сәгать».
21.15 Редакциягә хат килде. Тележурнал.
21.35 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Иртә.
9.05 «Бытбылдык елавы». 9 серия.
10.10 Кеше һәм закон.
11.25 Л. Гурченко башкаруында сугыш еллары җырлары.
12.00 ТЯХ.
12.15 Мультфильм.
12.35 Балалар сәгате.
13.35 Сәнгать һәм кооперация.
14.05 «Җыр-91».
15.00 ТЯХ.
15.15 Нәфис телефильм: «Ике тавыш өчен көй». 2 серия.
16.30 Һәвәсләр дөньясы.
16.45 Мультфильм.
17.00 Вьетнам. Гадәти көннәр һәм бәйрәмнәр.
17.45 ..16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк.
18.30 ТЯХ.
18.45 Мультфильмнар.
19.00 «Сугышны каһәр суксын». 4 нче фильм.
19.30 М. Равель. «Дафнис һәм Хлоя» балетыннан икенче сюита.
19.50 Җир—уртак йортыбыз. Фотоконкурс.
19.55 «Бытбылдык елавы». 9 серия.
21.00 Вакыт.
21.40 МВД хәбәрләре буенча.
21.55 Солдат җырлары фестивале.
00.10 ТЯХ.
00.30 СССРның Телевидение һәм радио буенча дәүләт комитетының симфоник һәм эстрада музыкасы оркестры концерты.
01.30 Док. фильм: «Байкал картлары».

**II ПРОГРАММА**

7.30 «Бридж». Телебиржа.
8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Халык көйләре.
8.30 Россия әйләнеп кара.
9.25 Мультфильмнар.
10.15 Нәфис фильм: «Әтисе, әнисе һәм балалары».
11.30 Юл. Социалистик Хезмәт Герое П. Малинина тормышының берничә көне.
12.20 Олег Басилашвили: «Ул нинди?»
13.20 Телефильм.
13.30 Балалар өчен фильм: «Малайлар». 1 серия.
14.40 Озын гомер...
15.25 Ритмлы гимнастика.
21.40 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
22.30 Музыкаль яңалыклар.
22.45 Григорий Бакланов: «Сүз сорыйм».
23.00 Хәбәрләр.
23.15 Криминаль канал: «Үтә яшерен».

**ҖОМГА**
**21 ИЮНЬ**
**ҚАЗАН ҚҮРСӘТӘ**

17.05 Док. фильм: «Гадәти фашизм». 1 серия.
18.30 Идел буе мөселманнары турында документаль фильм: «Аллаһе әкбәр» (М.).
19.00 Татарстан.
19.30 «Җомга көн кич белән» альманахы.
20.15 Тыныч йокы, нәниләр.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.45 Актуаль әңгәмә. Казан шәһәренең 12 нче клиник хастаханәсе коллективының аренда мөнәсәбәтләре шартларындагы хезмәте турында.
21.00 Фильм-концерт: «Җыр бүләк итәм».
21.35 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Иртә.
9.05 Мультфильмнар.
9.35 Концерт.
10.35 Мультфильм.
10.45 Чишмәләр.
11.15 ...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк.
12.00 ТЯХ.
12.15 Солдат җырлары фестивале.
14.30 Картлык шатлык булганда.
15.00 ТЯХ.
15.15 Нәфис фильм: «Эквилибрист».
16.30 Симфония №5 һәм 29.
17.00 Шигърият минутлары.
17.05 Балалар өчен фильм: «Кузгалып китәбез».
18.30 ТЯХ.
18.45 А. Скрябин. «Шашкын поэма».
19.00 «Сугышны каһәр суксын». 5 нче фильм.
19.30 С. Горшунов чыгыш ясый.
19.40 Нәфис фильм: «Сугыш вакыты законнары буенча».
21.00 Вакыт.
21.40 Актуаль интервью.
21.50 «ВиД» күрсәтә....
01.20 Док. фильм: «Төн уртасы һәм яңадан таң».

**II ПРОГРАММА**

7.00 Эшлекле кеше иртәсе.
8.00 Иртәнге гимнастика.
8.20 Мультфильм.
8.30 Док. фильм: «Тере планета». 3 серия.
9.25 Концерт.
9.40 Док. фильм: «Тартманы ач».
10.05 Фильм-концерт. «Безгә бу юлларны оныттырга ярамый».
10.50 Объектив.
11.30 Ватаныбыз һәйкәлләре.
12.10 К-2 күрсәтә: «Ирләрчә сөйләшү».
12.50 Симфоник миниатюралар.
13.30 Балалар өчен фильм: «Малайлар». 2 серия.
14.35 Кеше. Җир. Галәм.
21.40 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.25 Коллаж.
23.30 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
23.00 Хәбәрләр.
23.15 Бишенче тәгәрмәч.

# Экстрасенс хайваннар

Америкада «Үлемсез хайваннар» дигән китап басылып чыккан. Авторы—Билл Шул. Китапта сүз кыен хәлләрдә калган кешеләрне «йорт хайваннары фрәкләре» тарафыннан коткару турында бара.

Колорадодан Фрэнк Талберт үзенең өендә йоклап яткан булган. Урамда яшенле яңгыр яуган. Аны ишек артында эт чинавы уяткан. Ярдәм кирәктер, дип уйлап, Фрэнк ишекне ачкан да этне өйгә чакырган. Ә эт өйгә керми, киресенчә, әкрен генә артка чигенә башлый. Фрэнк фонарь алып, эт артыннан китә. Шулай итеп алар берничә дистә метрга өйдән читләшә. Һәм кинәт, өйне яшен сугып, йокы бүлмәсен тиз арада ут ялмап ала...

Күршеләренә барырга дип машинага утырганда Фрэнк үзенең гомерен саклап калган эт турында исенә төшерә. Ләкин эт беркайда да күренми. Ул бу вакыйганы күршесенә сөйләгәч, тегесе дулкынлана башлый: «Сурәтләвеңә караганда бу эт минем Сэндига охшаган. «Кайда ул? Мин аңа гомерем белән бурычлы».

Ә күршесе ишетелер-ишетелмәс кенә: «Сэнди ике ай элек үлде»,—дип җавап бирә.

...Шул ук шәһәр кешесе Робин Деланд тар гына тау буйлап төнлә машинада китеп барганда фаралар яктылыгында бер этне күрә. Робин тормозга баса һәм руль артында катып кала—ул эт аның алты ай элек үлгән Джеффы булып чыга. Робин, машинадан чыгып, Джеффны чакыра башлый. Ләкин тегесе алга—кискен борылышка таба китә.

Робин аның артыннан бара һәм юлда яткан зур ташны күрә. Әгәр ул машинада барган булса, бу ташны күрмәс иде һәм автомобиль упкынга төшеп китәр иде. Деланд якягына күз ташлый, Джефф күренми, ничек серле килеп чыкса, шулай югала.

..Рэй белән Сьюзен Петерс төнлә этләре Мак өргәнгә уянып китә. Рэй этнең тышка чыгасы килгәндер дип, торып утыра. Шул вакыт ул төтен исен тоя. Аның йокысы кача. Ваннада нәрсәдер яна.

Соңыннан ачыклануынча, күршесе үзенең ихатасында эт өргәнен ишетеп уянган да, янгын сүндерүчеләрне чакырган икән. Күршесе Рэйга: «Аллага шөкер, этегез вакытында уятты. Мак үлгәннән соң икенче эт алуыгызны белмәгән идем әле...Әйткәндәй, ул кая?»—ди.

Һәм шунда Рэй һәм Сьюзен таң кала. Бу вакытта алар икенче эт алмаган була. Чөнки Мак үлгәннән соң нибары өч кенә ай вакыт үтә.

**«Рассвет» совхозы администрациясе, партия, профсоюз һәм ВЛКСМ комитетлары, авыл Советы өченче бүлекчә агрономы**
**ХӘМИТ СӨЛӘЙМАН улы ФӘЙЗУЛЛИНның**
**кинәт үлүен белдерәләр һәм аның туганнары, якыннарының тирән кайгысын уртаклашалар.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81,, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. АСИЯ МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор—Рәзинә ШӘЙХУЛЛИНА.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе. Күләме—1 басма табак. Заказ 72. Тираж 3415.**